ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№ 129 от «15» 06 2021 г.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы
микросанын алуны әзерләү һәм үткәрү
буенча Комиссия төзү турында

«Бөтенроссия авыл хуҗалыгы санын алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 108-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 29 августындагы «2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны оештыру турында» 1315 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 30 декабрендәге «Татарстан Республикасы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләүне һәм уздыруны оештыру турында» 1265 номерлы карары нигезендә һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча җирле үзидарә органнарының килештерелгән гамәлләрен координацияләү һәм тәэмин итү максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Мамадыш муниципаль районында 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру Комиссиясен (килешү буенча) төзергә (2 нче кушымта).

2. Әлеге карага теркәлеп килүче «2021 елгы Мамадыш муниципаль районында авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру Комиссиясе турында нигезләмә»не (1 нче кушымта) расларга.

3. Мамадыш муниципаль районы авыл җирлекләре һәм Мамадыш шәһәре җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә яшәүче җирдән файдаланучылар турында белешмәләрне, аларга беркетелгән, 2021 елның 1 гыйнварына актуаль булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алу белешмәләре нигезендә, җир мәйданы һәм терлекләрнең баш санын күрсәтеп, билгеләнгән срокларда Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органына тапшыруны тәэмин итәргә;

Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органына тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарын авыл хуҗалыгы микросанын алу объектлары турында белешмәләр җыюга җәлеп итүдә, шулай ук

000142

авыл хуҗалыгы микросанын алу объектлары турында белешмәләр җыюны гамәлгә ашыручы затларны укыту һәм аларның эше өчен яраклы урыннар сайлауга, авыл хуҗалыгы микросанын алу кәгазьләрен һәм башка документларны саклау ярдәм итәргә;

2021 елда административ-территориаль һәм муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кормаска, шулай ук географик объектларның исемнәрен үзгәртмәскә;

4. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә эшләүче массакүләм мәгълүмат чараларына 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләүне һәм уздыруны мәгълүмати яктырту, авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру мәсьәләләре буенча мәгълүмати-аңлату эшләрен гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Мамадыш муниципаль
районы Башлыгы А.П. Иванов

Мамадыш муниципаль
районы башлыгы карары
«15» 06 2021ел, №129
1 нче кушымта

Мамадыш муниципаль районында 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру Комиссиясе турында
**Нигезләмә**

1. Мамадыш муниципаль районында 2021 елгы елның авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру комиссиясе (алга таба - Комиссия) җирле үзидарә органнарының килештерелгән гамәлләрен координацияләү һәм тәэмин итү, Мамадыш муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру мәсьәләләрен оператив хәл итү максатында төзелде.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, «Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 108-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 29 августындагы «2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны оештыру турында» 1315 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 30 декабрендәге «Татарстан Республикасы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләүне һәм уздыруны оештыру турында» 1265 номерлы карары нигезендә, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм күрсәтмәләре, Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре, Мамадыш муниципаль районы норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру комиссиясе карары, шулай ук әлеге Нигезләмә белән җитәкчелек итә.

3. Комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:
Мамадыш муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микрсанын алуны әзерләү һәм уздыру буенча җирле үзидарә органнарының килешенгән гамәлләрен тәэмин итү;
Мамадыш муниципаль районында 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле мәсьәләләрне оператив хәл итү;
Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы халкы арасында авыл хуҗалыгы микросанын алуны уздыру турында мәгълүмат-аңлату эшләрен башкару.

4. Үзенә йөкләнгән бурычларны башкару максатында комиссия түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:
авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләүнең һәм уздыруның, аның материалларын эшкәртүнең һәм авыл хуҗалыгы микросанын алу йомгакларын рәсми бастырып чыгаруның барышын тикшереп тора;
түбәндәге мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрне карый:

төрле оештыру-хокукый формасындагы оешмаларны Мамадыш муниципаль районында 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны уздыру эшенә җәлеп итү.

5. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

үз утырышларында Мамадыш муниципаль районы буенча федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Мамадыш муниципаль районы территориясендә җирле үзидарә органнары вәкилләренең 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру барышы турында мәгълүматларын тыңларга;

билгеләнгән тәртиптә Мамадыш муниципаль районы буенча федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары вәкилләрен, фәнни, иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмалар вәкилләрен, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларын комиссиясе эшенә җәлеп итәргә;

Комиссиягә йөкләнгән бурычларны хәл итүгә бәйле мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр эшләү өчен эшче төркемнәр төзергә.

6. Комиссия рәистән, рәис урынбасарыннан, Комиссия әгъзаларыннан һәм секретарьдан тора.

Комиссия рәисе Комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә, Комиссия утырышларының еллык планнарын раслый һәм Комиссия составын яңарту турында тәкъдимнәр кертә, аның утырышларын алып бара.

Комиссия рәисе булмаганда яисә аның кушуы буенча рәис вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

7. Комиссия утырышлары кирәк булуга карап, әмма ярты елга кимендә бер тапкыр үткәрелә. Ведомствоара комиссия утырышларын тиешле чыганакларга язып аудио- һәм видеоконференцияләр режимында уздырырга мөмкин.

Комиссия рәисе (ул булмаганда урынбасар) мәсьәләләрне карау тәртибен билгели, Комиссия утырышларының көн тәртибен раслый, Комиссия составын үзгәртү турында тәкъдимнәр кертә.

Комиссия утырышларының көн тәртибе авыл хуҗалыгы микросанын алуны үткәрү эшләре планы нигезендә Татарстан Республикасы буенча Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең территориаль органы тәкъдимнәре нигезендә төзелә.

Комиссия әгъзалары Комиссия утырышларында шәхсән үзләре катнаша һәм Комиссия утырышында карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышканда тигез хокукларга ия.

Комиссия утырышы, әгәр анда әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, хокуклы дип санала.

Комиссия әгъзалары һәм чакырылганнар докладларчылар докладлар белән чыгыш ясый, тәкъдимнәр кертә, тикшерелә торган мәсьәләләрнең асылына белешмә бирә ала.

8. Комиссия карарлары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, рәис тавышы хәлиткеч булып тора (ул булмаганда урынбасарныкы).
Комиссия утырышында кабул ителә торган карарлар комиссия утырышының беркетмәләре рәвешендә рәсмиләштерелә.
Карарларга Комиссия рәисе (ул булмаганда, аның утырышта рәислек итүче урынбасары) имза сала.

9. Комиссия эшен оештыру-техник тәэмин итү Федераль дәүләт статистика хезмәтенең Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы буенча территориаль органы белгечләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Мамадыш муниципаль
районы башлыгы карары
«15» 06 2021ел, №129
2 нче кушымта

Мамадыш муниципаль районында 2021 елгы
авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру
Комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Иванов Анатолий Петрович | Мамадыш муниципаль<br>районы башлыгы, Комиссия рәисе |
| Гаптрахимов Ильяс Габделхай улы | Мамадыш муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы, комиссия рәисе урынбасары |
| Хәбибуллина Фазилә Гаяз кызы | Дәүләт статикасының<br>Алабуга шәһәрендәге бүлегенең (Мамадыш ш.) әйдәп баручы белгеч-эксперты,- комиссия секретаре |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Сәмигуллин Ришат Роберт улы | Мамадыш муниципаль районы башлыгы урынбасары |
| Дәрҗеманов Илшат Миннәсхәт улы | Башкарма комитет җитәкчесе |
| Никитин Вадим Ильич | Башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасары |
| Усачев Леонид Борисович | Россия Эчке эшләр министрлыгының Мамадыш районы буенча бүлеге башлыгы |
| Һадиуллин Ленар Хәлим улы | Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе |
| Ханова Светлана Наилевна | «Татамедиа» АҖ филиалы “Мамадыш – информ” баш мөхәрире – җитәкчесе |
| Яруллина Сәрвиназ Якуб кызы | ТР буенча Росреестр идарәсенең Мамадыш бүлеге җитәкчесе |